# ИЛДУС ГЫЙЛӘҖЕВНЕҢ МӘХӘББӘТ ЛИРИКАСЫНДА ШӘХЕС ГӘҮДӘЛӘНЕШЕ

Һәркем шигъриятькә үз сүзен әйтергә килә. Илдус Гыйләҗев диюгә үк, аның турында бертавыштан «җир шагыйре» диләр. Илдус Гыйләҗевнең һаман тулыланып торган шигъри мирасын барлаганда һәм бәяләгәндә, җыентыкларындагы гаҗәеп пөхтә тематик төркемнәргә тап буласың. Туган җир, авыл, игенчелек; әнкәй, гаилә, мәхәббәт, яшәеш һәм иҗат фәлсәфәсе; әхлак, туган тел, милли азатлык, һәм шулар арасындагы башка бик күп тематик катламнарда шагыйрьнең шәхес концепциясе үсеше юл ала. «Җилкенү» (1990), «Серле мәгарә» (1995), «Хак сүз» (2000), «Чатыртау тылсымы» (2001), «Яратканга күрә» (2006) дип аталган шигырь китапларында эстетик идеалы үскәннән-үсә, тулы канлылана барганлыгы күренә. Шагыйрь күзаллаган шәхес төрле яктан ачыла һәм, камилләшә барып, каләм иясенең бердәм сәнгати карашын тәшкил итә, аның иҗатының этәргеч көчен, әйтәсе сүзенең мәгънәви асылын билгели.

Яшәешне һәрдаим үзгәрештә, үсештә күзаллау Илдус Гыйләҗев иҗатында шәхеснең рухи үсешенең дә үзәк ызанын хасил итә. Шагыйрь тудырган шәхеснең тормыш фәлсәфәсенә һәрдаим яну, әрле-бирле чабу, эзләнү, камилләшү хас. Ул кешеләр бәхете өчен үзен аямыйча егылганчы бара торган мосафир кыяфәтендә дә, башкаларга юлны яктырту өчен күкрәгеннән йөрәген тартып чыгарган Данко ихтыярында да күз алдына баса. Аның максаты — алга, фәкать алга бару. «Мәңгелек хәрәкәт» шигырендәге:

Иртән торсам, чабам әрле-бирле,
Нидер эзлим һаман.
Яктылыгым төшсен кешеләргә! —
Дөрли-дөрли янам, —

дигән юллар шәхес үсешенең асылын тәшкил итә. Әлеге шигырь — Илдус Гыйләҗев шигъриятендәге мәхәббәт лирикасының алтын таҗы. Мәхәббәтнең иң киң һәм тирән мәгънәсен үз эченә алган, яшәешкә, кешелеккә карата ихлас хисләр белән сугарылган бу юллар шагыйрь иҗат иткән эстетик идеалның югары багланышын гәүдәләндерә. И. Гыйләҗевнең мәхәббәт лирикасы үзенең фәлсәфи уйланулары һәм нәтиҗәләре, шуннан килеп туган афоризм дәрәҗәсендәге тыгыз мәгънәле гыйбарәләре, шулай ук җылы юморы, шаярту, төрттерү белән күпкырлы һәм бай.

Шагыйрь өчен мәхәббәт ул — сагыш әчесе дә, сагыну да, чырагачка калып ябыгу да, көнләшү, шикләнү газабы да, хәйлә кору, моңга чуму, җырлап тилереп йөрү дә.

Шулай булмаганда нигә кирәк
Килеп-китеп йөрү, сөйрәлеп.
...Мәхәббәтне зурлап яшәдек без,
Шашып яратырга өйрәнеп, —

дип, ул үзенең мәхәббәт концепциясен шәрран ачып сала «Гадиләштермә мәхәббәтне» шигырендә.

Сөю халәтенә фәлсәфи, тылсымлы күзлектән карап, әкияти романтикага юл алу, образлы нәфислеккә юл тоту мондый шигырьләрнең шагыйранә яңалыгын тәшкил итә. «Икебезнең әҗәт» шигырендә дә лирик герой, сөйгәне образына мөрәҗәгать итеп, гаҗәеп табигый, нәфис сурәт тудыра.

Гаҗәпләнмә, һава тып-тын чакларда да
Чәч толымың куйса уйнаклап —
Мин йөрим ул... Мыштым гына барып киләм,
Уем белән сине кочаклап.

Шигырьдәге үзгә бер моң, авазлар тибрәнеше, ритмнар төгәллеге бу юлы авторның замандашы мәрхүм Наис Гамбәр тавышын ишеттергәндәй була.

Гаҗәпләнмә: бер көн өй каршына
Кошлар җиккән арба туктаса,
Күңел кошлары ул:
Такыя үр, Ләйсән,
Кошлар биргән гөлдән чук ясап, —

дип язган иде ул «Күңел кошлары» шигырендә. Н. Гамбәрдә романтиклык хыял югарылыгында тотып алынса, И. Гыйләҗев романтизмы җиргә, чынбарлыкка якынрак халәттә рухи яшәешне нәфис итеп тасвирлау йөкләмәсен ала. Әсәрдәге вакыйгалар динамикасына, драматизмга, психологиягә ирешүдә ике шагыйрь дә шигъри калыптан, поэтик мөмкинлекләрдән, урынлы кулланылган паузалардан отышлы файдаланган.

Әлеге шигырьдә И. Гыйләҗев тормышка, мәхәббәткә фәлсәфи караш ягыннан да отышлы ысулга мөрәҗәгать итә. *«Минем алачагым, синең бирәчәгең бармы? Синең янга һаман тартылам»,—* дип, үзенең мәхәббәтендә, фәлсәфә фәнендәге мөһим закон

буларак, сәбәп һәм нәтиҗә бәйләнешен нигез итеп ала. Алай гына да түгел, сөйгәне белән мөнәсәбәтен аклау өчен ул илаһи кануннарны да сәбәп итеп ала:

...Без, мөгаен, икәү дөнья каршысында,
Хода каршысында әҗәтле...

Тормыш тәҗрибәсенең сөземтәсе буларак туган фикер төгәллеге һәм мәхәббәт лирикасындагы үзгә бер әверелешне күзаллавы ягыннан «Мин божрада» шигыре дә гыйбрәтле. Кеше күңеле гомер буе камиллек, гүзәллек эзли, иң зур табыш еш кына янәшәдә булып чыга. Кеше шушы рәвештә үз асылына кайта, аның аң-фикер үсеше шуны таләп итә:

Синнән башланам да синдә бетәм
Бoҗра сыман.
...Бөгелергә Ходай үзе
Боера сыман...

Әлеге фикер «Шулай булачак», «Җиңелеп җиңү», «Бер фәлсәфә» шигырьләрендә дә төрле яклап ачыла. Мәхәббәт фәнен яхшы үзләштергән, хисләр дөньясында кыйбласын югалтмаган лирик геройның бу юлы да чыгарган нәтиҗәләре илаһи кануннарга нигезләнә. «Бер фәлсәфә», «Түләү» шигырьләрендә дә хисләр дөньясында хакыйкатькә инану, язмыш белән килешү, чын мәхәббәтне, бәхетне тану сөю лирикасының эчке бөтенлеген хасил итә.

Мәхәббәт дөньясында афористик яңгырашлы кануннар булдыру И. Гыйләҗев иҗат иткән шәхеснең әхлакый тормыш принципларын формалаштыра. Мәсәлән, «Бәхетнең бер төре» шигырендә лирик каһарман яшьлеккә, гүзәллеккә сокланган гөнаһсыз һәм ихлас зат буларак күз алдына баса. Һәм, үзенең дөньяга карашын аклап, мондый нәтиҗәгә килә:

Чибәр кызлар тулы бу дөньяда
Яшәп киту — үзе бер бәхет.

«Эш узгач» шигыре дә лирик геройның тирән кичерешле, катлаулы хисләр дөньясында күп еллар узгач калкып чыккан хакыйкатьне тануы белән гыйбрәтле. Табыну, сагыну узган заман яссылыгында «ялгыш» дип бәяләнсә дә, еллар узгач, шул ялгышларның табыш булганлыгына инану калка. Хронотоп яки вакыт һәм пространство берлеге башка шигырьләрдә дә фәлсәфи нәтиҗәләрнең

нигезе булып тора. Ике вакыт яссылыгында барган вакыйгахәлләрне чагыштыру тыгыз фикерле, эмоциональ тәэсирле, инандыргыч көче булган сөземтәләргә алып килә. «Түләү» шигырендә җиңгән ханбикәгә шигырь белән ясак түләп торучы әсирнең, «Еллар шәүләсе» шигырендәге еллар хозурында тәмам йончыган лирик геройның күңел халәтен билгеләү ике вакыт яссылыгында бара. Зур тормыш тәҗрибәсе, хисләр дөньясындагы сөземтәләр мәкальгә тиң тезмәләр хасил итә.

Ундүрт яшьтә елап яратмаган
Егермедә чынлап яратмас.
*(«Ундүрттә, егермедә»)*

Көнләштереп кенә бөгеп була
Баш бирмәгән горур егетне.
*(«Хәзер үзем көнләштерәм»)*

Мәхәббәттән качып бәхет тапкан
Кеше әле җирдә булмаган.
*(«Күрәзәче булмасам да»)*

Сөю көче көчсезлектә.
*(«Иң бөек көч»)*

Ялган сүз дә ышандыра,
Ышанасың килгәндә.
*(«Хак шулай»)*

Лирик геройның күңелендә яралып, эволюция кичереп, вакыт сынавын үтеп чыныккан хисләр әнә шундый афоризмнар тууына сәбәп булган.

Шагыйрьнең мәхәббәт теориясе төрле парадоксларны эшкә җигү юлы белән дә сөю көченең психологик тирәнлеген ачарга мөмкинлек бирә:

Томаланды ихтыярым,
Рисвайлар иттерден.
Хушлашам дип килгән идем,
«Яратам!» — дип әйттердең...
*(«Үзгәреш»)*

Юк, автор лирик геройның көчсезлегенә, ихтыярсызлыгына түгел, ә шәхес белән идарә итүче эчкерсез хисләрнең илаһи көченә ишарәли бу юлы. «Матурлык колы» шигырендә дә мәхәббәтне илаһилаштырып, шагыйрь *«Эреде дә бетте менә Гомер буе җыйган акыл...»* дип, рухи, хисси эволюцияне гаҗәеп җыйнак формада ачып бирә.

И. Гыйләҗевнең мәхәббәт шигырьләрендә гыйшыклык халәтенә җиңелчә ирония, җылы юмор белән карау да сиземләнә.

«Сөйкемле була беләсең» әсәрендәге кыз чәүкә белән янәшә утырган егет чәүкәнең кыяфәтенә генә карагыз! Берничә юл эчендә автор аның холык-фигылен, килеш-килбәтен җете төсләр белән койган да куйган. Монда халыктагы «Сылу сылу күренми, сөйгән сылу күренә» дигән мәкальгә ишарә бар. Әнә бит, сөйләшергә яратмыйча, төксе генә утырган, каурыйлары тырпаешкан, канатлары шәлперәйгән «егеткә» «кыз чәүкә» ничек сөеп карый. Күп шигырьләрдәгечә, биредә дә автор үз моралең үзенчә җиткерә: *«Чибәрләр бер читтә тора, Була белсәң сөйкемле».* Шигъри карикатура тудырганда, сүз остасы «янәсе», «мөгаен», «ярабби», «икән» «шикелле» кебек кереш һәм ярдәмлек сүзләрдән отышлы файдаланган. Автор, гомумән, шигъри сүзнең егәрен катлаулы сүзтезмәләрдән, хикмәтле символикадан түгел, ә халык теленең үткенлегеннән таба.

Мәхәббәт призмасы аша хакыйкатьне эзләү, кеше тарафдарының тормыш мәгънәсен шигъри табышларда яктырту фәлсәфи, тормышчан кануннарга алып килә:

Мин — һаман яшь! Яныл-шашып
Яратканга күрә, —

дип, вәкарь белән яңгырата ул үз гыйбарәсен. Ярату шагыйрь өчен тормыш принцибы, дөрес яшәү шарты, картаймау, көчсезләнмәү, бетәшмәү сере булып ачыла.

Әдәбият ул — кеше турындагы фән дибез без. Моңа өстәп шигърият ул — кешенең хакыйкатькә бару юлы, аның рухи камилләшү ызаны, иманга килү ноктасы диясе килә. Аллаһы Тәгаләнең ымын сизеп каләмгә тотынган һәр яшь каләм иясе үзен аптыраткан һәм хозурландырган күренешләрне, тәүге хисләрен дәфтәр битләренә терки бара. Гадәти генә темаларны яңача ачып, шигърияттә үз табышын калдырырга омтыла. Туган туфракка булган изге хисләр, милләткә булган әрнүле мәхәббәт Илдус Гыйләҗевтә дә, шигърият чишмәсе булып ургып, зур иҗат дәрьясына таба юл ала. Менә шушы ике биеклек аның шигъриятенең таҗы булып каладыр да, мөгаен.

Шагыйрь соңгы елларда актив эшли. Шунысы сөенечле: ул, күп язса да, үз-үзен кабатлау боҗрасына керми, яңа, заманча темаларга мөрәҗәгать итә, әдәп, әхлак, татарлык, мөселманлык, иманга кайту турында уйлана: